Зарегистрирован
в Управлении Министерства юстиции
Российской Федерации в Республике Татарстан
Свидетельство о государственной регистрации
Устава муниципального образования город
Нижнекамск Нижнекамского муниципального
района Республики Татарстан
№ RU165301172021001 от 15 апреля 2021 года


РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru


**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2021 елның 22 марты № 10

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының
Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр
һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28, 44 статьялары, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 94, 95, 96 статьялары нигезендә, Түбән Кама шәһәр Советының «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен игътибарга алып, Түбән Кама шәһәр Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама шәһәр Советының 2016 елның 14 апрелендәге 17 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына кушымта нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.
2. Әлеге карар гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә, 2021 елның 7 июненнән үз көченә керә торган әлеге Карарга кушымтаның 6 пунктыннан тыш, үз көченә керә
3. Түбән Кама шәһәре Мэрына (А.Р.Метшин) әлеге карарны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алуга җибәрергә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама шәһәр Советының регламент, җирле үзидарә һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры А.Р. Метшин

Түбән Кама шәһәр Советының
2021 елның 22 мартындагы
10 номерлы карарына
кушымта

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр

1. «Шәһәрнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә кертелмәгән мәсьәләләрне хәл итүгә шәһәрнең хокукы» 7 статьясына түбәндәге эчтәлекле 17 һәм 18 пунктлар өстәргә:

- 17) полиция участок вәкаләтлесе вазыйфасын биләгән хезмәткәргә һәм аның гаилә әгъзаларына хезмәткәр тарафыннан күрсәтелгән вазыйфаны биләү чорында торак урыны бирү;

- 18) алкогольле, наркотик яки башка токсик исерек хәлдә булган затларга ярдәм күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру.».

2. «Шәһәр халкы тарафыннан җирле үзидарәне турыдан-туры гамәлгә ашыру һәм халыкның җирле үзидарәне гамәлгә ашыруда катнашуы формалары» 13 статьясында 1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 12.1 пунктча өстәргә:

- «12.1) инициативалы проектлар);».

3. «Территориаль иҗтимагый үзидарә» 19 статьясында:

а) 9 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 7 пунктча өстәргә:

7) инициативалы проект буенча фикер алышу һәм аны хуплау мәсьәләсе буенча карар кабул итү.»;

б) 10 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 5 пунктча өстәргә:

«5) проект инициаторлары сыйфатында инициативалы проектны тәкъдим итә алалар.»

4. «Гражданнар җыелышы» 23 статьясында:

а) 1 өлешкә «һәм шәһәрнең җирле үзидарәсе вазыйфаи затлары,» сүзләреннән соң «инициативалы проектларны кертү һәм аларны карау мәсьәләләре турында фикер алышу» сүзләрен өстәргә.

б) 2 өлешкә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Инициативалы проектларны кертү һәм аларны карау мәсьәләләре буенча гражданнар җыелышында уналты яшькә җиткән тиешле территориядә яшәүчеләр катнашырга хокуклы. Гражданнар җыелышын билгеләү һәм үткәрү тәртибе, инициативалы проектларны кертү мәсьәләләрен карау һәм фикер алышу максатларында, шәһәр Советының норматив хокукый акты белән билгеләнә.».

5. «Гражданнарны сораштыру» 25 статьясында:

- 2 өлешкә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Гражданнарның инициативалы проектка ярдәм итү турындагы фикерен ачыклау мәсьәләсе буенча үткәрелгән сораштыруда уналты яшькә җиткән, инициативалы проектны гамәлгә ашыру тәкъдим ителә торган муниципаль берәмлек яки аның өлешендә яшәүчеләр катнашырга хокуклы.»;

- 3 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә: «3) уналты яшькә җиткән инициативалы проектны гамәлгә ашыру тәкъдим ителә торган муниципаль берәмлек яисә аның өлешендә яшәүчеләр - әлеге инициативалы проектка ярдәм итү турында гражданнарның фикерен ачыклау өчен.»;

- 5 өлешнең беренче абзацында «шәһәр Советы тарафыннан кабул ителә» сүзләреннән соң «Гражданнар арасында сораштыру үткәрү өчен «Интернет»

мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайты файдаланылырга мөмкин (http://www.e-nkama.ru).» җөмләсен өстәргә;

- 5 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 6 пунктча өстәргә:

«6) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтын кулланып гражданнар арасында сораштыру уздырган очракта, сораштыруда катнашучыларны идентификацияләү тәртибе (http://www.e-nkama.ru).»

- 7 өлешнең 1 пунктында «шәһәрнең җирле үзидарә органнары» сүзләреннән соң «яки муниципаль берәмлек халкы инициативасы буенча» сүзләрен өстәргә.

6. «Шәһәр Уставы, әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карар үз көченә керү тәртибе» 96 статьясында:

- 2 өлешкә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Шәһәр Мэры муниципаль берәмлек Уставы турында, муниципаль берәмлек уставына үзгәрешләр кертү турында муниципаль хокукый акт турында мәгълүматны «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясындагы 6 өлешендә каралган Россия Федерациясе субъектының муниципаль берәмлекләр уставының дәүләт реестрына кертү турында хәбәрнамәне муниципаль берәмлекләр уставларын теркәү өлкәсендә федераль башкарма хакимият органының территориаль органыннан кергән көннән 7 көн эчендә теркәлгән шәһәр Уставын, шәһәр Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый актны бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) бурычлы.».

Түбән Кама шәһәре
Мэры урынбасары М.В. Камелина